| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ**<br>10 июля 2015 года | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>№543 |

Зеленодольск муниципаль районы Советы 2014 елның 30 июнендәге 415 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Зеленодольск муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе Н.В. Гусевның Зеленодольск муниципаль районы Советы 2014 елның 30 июнендә кабул ителгән 415 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советы 2014 елның 30 июнендәге 415 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган, хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында»гы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга кушымтаны түбәндәге юллар белән тулыландырырга:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «14 | Торак булмаган бина №1000 | Зеленодольск шәһәре, Норкин урамы, 3 йорт | 156,4 |
| 15 | Торак булмаган бина №1001 | Зеленодольск шәһәре, Норкин урамы, 3 йорт | 42,0 |
| 16 | Бина | Зеленодольск районы, Маёвка авылы , Школьная урамы, 1 йорт | 194,6». |

2. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтына (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**